ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«27» нче август 2020 ел** **№ 389**

**Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында, 2020 елның 1 апрелендәге 71-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга, 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» (Советның 07.08.2019 №307, 16.10.2019 №316, 19.03.2020 №363 карарлары редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 7 пунктындагы 1-3 абзацлары:

«күрсәтелгән юридик затларның милкендә булган» сүзләреннән соң беренче абзацны «(федераль законнарда билгеләнгән очракларда күрсәтелгән юридик затлар милкендәге яисә дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына күрсәтелгән юридик затлар тарафыннан элегрәк гамәлгә ашырылган капиталь кертемнәргә бәйле рәвештә чыгымнарны каплауга)» сүзләре белән тулыландырырга;

икенче абзацны «әлеге пунктның,» сүзләреннән соң «капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга» сүзләре белән тулыландырырга;

өченче абзацта «алынган акчалар исәбеннән» сүзләрен «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда дәүләт (муниципаль) милкенә тапшырылырга тиешле

капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү) максатларында сатып алуларга алынган акчалар исәбеннән,» сүзләре белән алыштырырга, «тыш» сүзеннән соң «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән чыгымнарны каплауга субсидияләр, һәм» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 6 статьяның 2 пунктын, 20 статьяның 2 абзацын, 28 статьяның 3 пунктындагы 14 абзацын, 35 статьяның 1 пунктын, 38 статьяның 3 пунктын һәм 5 пунктындагы 1 абзацның гамәлдә булуын туктатып торырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб - адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин